# Мәктәп хәбәрчесе

№7
(№10)
сентябрь
2019 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газите
Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

**БУ САН БАЛАЛАР БАКЧАСЫНА БАГЫШЛАНА**

*/Өлкәннәр киңәше/*

**БУЙСЫНМАГАН БАЛАГА ҖӘЗА БИРҮ ТИЕШМЕ?**

Җәмгыяттә кабул ителгән тәртип һәм нормаларны үтәмәүчеләргә карата төрле тискәре санкцияләр, халык телендә әйткәнчә, җәза куллану каралган. Кешенең тәртипле тормышка күндерү сабый чактан ук башланырга тиешлеген күздә тотсак, тыңламаган балаларга тиешле җәза бирү үтемле тәрбия чарасы булып тора. Ләкин бу мәсьәләгә килгәндә, кайбер әти-әниләр балага карата ничек дөрес итеп җәза бирү ысулларын белмиләр, ә кайсылары исә, "җәза" сүзенең мәгънәсен дә аңлап бетермиләр.

**Һәр эштә "алтын урталыкны" табу тиешле**

Кайбер ата-аналар тәртипсез балаларга җәза бирүне кабул итә алмый. Балага борчу китермичә генә аның җаена бару, ни теләсә шуны үтәү юлы кулайрак дип уйлый. Бу йомшак әти-әни алымы һәм бу юл һәрвакыт үзен акламый: иртәме, соңмы бала үзенең ярларыннан чыга, әти-әни нишләргә дә белми торган хәлдә кала.

Боларга капма-каршы булган авторитар әти-әниләр "бала буйсынмаса, кырыс җәза кулланырга кирәк, бу иң кулай алым" – дип исәплиләр. Мондый әти-әниләр үзләренең тоткан урыны һәм көче баланы гына буйсындыра алырга тиеш дип уйлый. Ләкин бу мөнәсәбәт баланы тагын да күбрәк явызландыра һәм кирелеген арттыра гына төшә.

**Балага җәза бирүнең мәгънәсе нәрсәдә?**

Әти-әниләргә җәза һәм шелтәләрнең мәгънәсен, аның нәрсәгә китерүен аңлау, үзара килешеп эшләү бик мөһим. Җәзаның мәгънәсен баланы куркыту, авырттыру, кыерсыту дип аңлау ялгыш фикер. Дөрес, авырту һәм курку баланың исендә калып, ярамаганны эшләүдән тыелып торырга мәҗбүр итә. Ләкин бу очракта бала төрле тәртипсезлекләрдән үзе теләп түгел, ә өлкәннәргә ярарга тырышып, икейөзләнеп кенә тыела. Куркыту юлы белән тәртипкә күндерелгән балалар, гадәттә җаваплылыктан котылу өчен алдашу юлына басалар. Кырыс җәза алымы кешенең үз-үзен тотышын үзгәртә алса, төрмә һәм колония нәтиҗәләре һәрвакыт уңай булыр иде.

"Дөрес җәзаның" мәгънәсе – балаларга тормыш кагыйдәләрен төгәл үтәүне җиткерүдә. Бала өлкән кеше сүзенең әһәмиятле һәм бик җитди икәнен аңлап кабул итәргә тиеш. Кайбер балалар әти-әни сүзенә бик җиңел карыйлар. Ә "дөрес җәза"аның күңелендә борчылу, оялу һәм уйлану хисләре барлыкка китерә. Әти-әни дөньяда баласының ышанычлы яклаучысы, дөрес яшәү кагыйдәләрен өйрәтүче "олы маяк" булырга тиеш. Үз теләге һәм иркенә буйсындыручы гына түгел. Бу аның сөйләмендә дә чагылырга тиеш: "Мин әйттемме..." яки "Мин куштым бит..." кебек сүзләр урынына, "Безнең гаиләдә болай эшләү кабул ителгән...", "Бездә шундый тәртип..." дигән сүзләр белән башлап сөйләү бик мөһим. Күргәнебезчә бу фразаларда "Мин" сүзе төшеп кала, баланың күңеленә тия торган боеру сүзләре урынына аны киреләндерми торган, ә уйландыра торган сүзләр кулланыла. **(Ахыры өченче биттә)**



**"Безнең бакча ". Нурматова Асия. 6 яшь.**

## 27 СЕНТЯБРЬ – ТӘРБИЯЧЕЛӘР КӨНЕ

Бәхетле балачак һәрберебезне гомер буе озата бара. Һәр сабыйның киләчәк тормышы аны кечкенәдән тәрбия кылучының зирәклеге, игътибары, сабырлыгына бәйле. Аларның күңел дөньясына ачкыч таба белү, һәр теләген аңлау да зур тырышлык сорый. Сездә шул осталыкларны күрү, кайгыртуыгыз, сәләтләрен ача белүегез бездә соклану белән хөрмәт уята.

Сезгә, хөрмәтле тәрбиячеләр һәм бакча хезмәткәрләре, барлык тырышлыгыгыз, балаларны яратуыгыз өчен олы рәхмәтләр әйтәбез. Киләчәктә дә уңышлар, мәңге сүнмәс иҗат, балаларның мәхәббәтен тоеп эшләргә насыйп булсын. Гаиләгезгә дә сәламәтлек, иминлек, тыныч тормышлар телибез.

***Барча мәктәп коллетивы исеменнән***
***"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегия***





*/Рәсми хәбәрләр/*

**2019/2020 УКУ ЕЛЫ БАШЛАНДЫ**

2 сентябрь көнне Белем бәйрәме белән яңа 2019/2020 уку елы башланды. Җәйге каникул көннәрендә мәктәп бинасында агымдагы ремонт эшләре башкарылды. Район мәктәпләренең уку елына әзерлеген тикшерүче комиссия безнең мәктәпне кисәтүләрсез кабул итте. Җәй айларында безнең мәктәп “ЛУКОЙЛ” акционерлык җәмгыятенең социаль һәм мәдәни проектлар конкурсында катнашып, 100 000 сумлык грант отты. Әлеге акчалар спортзалга көрәш паласы алу өчен тотылачак.

Яңа уку елы башына 1-11 сыйныфларга 55 укучы, бакча төркеменә 11 тәрбияләнүче килде. Шулардан 2 укучы һәм 1 тәрбияләнүче Иске Татар Әдәмсуы филиалында белем алачак. Барлык укучыларга һәм мәктәп хезмәткәрләренә уңышлы уку еллары теләп калабыз.

*/Мәктәп тормышы/*

**КӨЗГЕ БАКЧА МУЛЛЫГЫ**



Һәр ел фасылының үзенә генә хас сихри матурлыгы бар. Безгә күңелле җәйдән соң кәрзиненә муллык төяп көз килде. Менә шуна күрә, уку елы башы Белем бәйрәме белән генә түгел, көзге байлыгы белән дә уңышлы. Җәйге хезмәтләргә нәтиҗә ясап, бакчабыздан төрле яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне саклауга салу өчен тагын бер кат тырыш хезмәт куябыз. Барлык укытучылар һәм укучылар белән бергәләшеп мәктәп бакчасыннан бәрәңге алдык. Аның муллыгы быел аеруча күренде, чөнки икенче икмәгебез күп булды. Кишер, чөгендерләр дә берсеннән-берсе узып зур үскәннәр. Аларны ашханәгә дә, саклау өчен базга да салдык. Үзебез өчен кышкылыкка ризык әзерләү безгә күңелле хезмәт кенә. Күмәк эш тау күчерә дигәндәй, бик тиз генә бакча эшләрен тәмамладык та, барлык көчләрне туплап укырга килдек.

***Виктория Нукина,VIII сыйныф укучысы***

**Җәза бирүдә нәрсә ярамый?**

- Баланың ялгышын вакытында кисәтергә кирәк, игътибарсыз калдырырга яки вакытын кичектерергә ярамый! “Дөрес җәза” алымы тәртип кагыйдәләре бозылуга, үзен дорфа тота башлауга ук кулланылырга тиеш. Моның кечкенә яшьләрдән үк катгый үтәлүе шарт. “Бүгенгә генә ярар инде” дип йомшарып, без баланың аңын үзебез бутыйбыз. Аннары үтәмәсә аны ачуланабыз, бу ата-ананың наданлыгы.
- “Кырыс җәза” алымын куллану тыела. Җәза бары тик баланың баш миенә “тәртипне бозарга ярамый” дигән сигнал җибәрүдән гыйбарәт булырга тиеш.
- Җәза бирәм дип, баланы кимсетергә ярамый. Димәк, кырыс тавыш белән кычкыру, мәрхәмәтсез, баланы түбәнсетә торган сүзләр әйтү тыела.
- Балага тән җәрәхәте бирә торган җәза куллану катгый тыела. Бу аны кимсетеп кенә калмый, ә күңелен кырысландыра, бала белән мөнәсәбәтләрне боза, аның шәхес буларак үсешен тоткарлый.

**Истә тоту мөһим!**

- Өлкәннәр ризасызлык белдергәндә һәм ничек итеп моны төзәтеп булуын аңлатканда, балага мөмкин кадәр кыска һәм аңлаешлы итеп сөйләү мөһим.
- “Дөрес җәза” кулланучының мөмкин кадәр тыныч күңел һәм мәрхәмәтле тавыш белән сөйләшүе мөһим.

Әлеге мәкалә балалар психологиясен өйрәнгән күренекле галимнәрнең фикерләре буенча төзелде. Аның дөреслеге тормыш тәҗрибәсендә дә сыналганга күрә сезгә дә тәкъдим итәргә булдык. Җәза бирү никадәр авыр һәм җитди гамәл булган кебек, аның турында язу да шундый ук җаваплы бер гамәл икән. Шуңа да безнең газиз балаларыбыз тәрбиясендә мондый чикләргә килеп җитмәсәк иде. Үзебезгә хәерле, хөрмәтле әти-әниләр булырга, балаларыбызга күркәм үрнәк булырга Аллаһы Тәгалә насыйп итсә иде.

***Гөлүсә Насыйрова. Бакча төркеме тәрбиячесе***

***/Күренекле шәхесләр/***

## АВЫЛДАШЫБЫЗ – БАЛАЛАР БАКЧАСЫ ВЕТЕРАНЫ

Түбән Майна авылында гомерләрен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган Рафик абый белән Асия апа Исмәгыйлевлар гаиләсе яши. 27 сентябрь – тәрбиячеләр көне уңаеннан, хәбәрчеләребез балалар бакчасында озак еллар мөдир булып эшләгән, РСФСРның мәгариф отличнигы, хезмәт ветераны Асия апа белән очрашты.

**- Асия апа, һәркем педагог була алмый, ул кешегә тумыштан килгән халәттер, ә Сез бу юлны ничек сайладыгыз?**

- Мин балалар бакчасында 25 ел эшләдем. Әлбәттә, очраклы хәл булмагандыр анда эшләп китүем. Тәрбияче иң беренче чиратта бала җанлы, эчкерсез һәм ягымлы булырга тиеш, чөнки балачак – кеше тормышының иң мөһим чоры. Сабыйга кемнәр якын дус, яклаучы була ала, аларның һәр нәни шатлыгын, борчуын күрә белгән кеше генә эшли ала анда.

**- Һәр бала үзенчәлекле, аларның һәрберсенең теләге төрле, аларны уртак теләккә ирештереп эшләү өчен олы сабырлык таләп ителә. Меңтөрле сорауга җавап та табарга кирәк. Моның нинди юлларын таба идегез?**

- Иң беренче сыйфат - балаларны чын күңелдән яратырга кирәк. Сизгер җанлы балалар синең яратуны тиз тоялар. Сабыйларның һәр шатлыгын да бүлешә идем. Матур күлмәк алганмы, яңа уенчык алганмы - болар безнең күздән дә, игътибардан да читтә калмаска тиеш инде.

**- Сезне балалар әкият остасы дип тә искә алалар.**

- Мин көн саен әкиятләрне дөньяда матурлыкның күп булганын, яхшы сыйфатларның һәрчак җиңеп чыкканын аңлатыр өчен күбрәк басым ясап, үзем иҗат итеп сөйли идем.

**- Асия апа, Сез эшләгән елларда төркемнәрдә ничәшәр бала йөри иде?**

- Мин эшләгәндә 30-32 бала йөри иде. 32 балага 20 урын булды. Авыр вакытлар булса да, тәрбияче Гафиятуллина Фәридә, Гафиятуллина Флера, Гөбәйдуллина Гөлсинә апаларыгыз белән тату эшләгәнгә ул авырлыклар сизелмәгән. Алар һәрберсе балаларны яратып озак еллар эшләделәр.

**- Сезгә тәрбияче булумы, әллә җитәкче булу авыр тоелдымы?**

- Икесе дә зур тырышлык сорый торган хезмәтләр. Хезмәтнең чын күңелдән яратып башкарылганы, җаваплылык тоеп эшләгәне генә уңыш китерә. Йөкләнгән хезмәтнең кайсы да күңелгә якын булса гына башкарып чыгып була.

**- Асия апа, бүгенге тәрбиячеләргә нинди киңәш бирер идегез?**

-Тәрбиячегә төп сыйфат сабырлык, тыйнаклык телим. Үз белемеңне һәрвакыт күтәрергә, укырга кирәк. Яңалыклардан хәбәрдар булырга һәм балаларны яратырга кирәк.

***Әңгәмәне VIII сыйныф укучылары***
***Виктория Нукина һәм Зөлфирә Сафиуллина язып алды***

Асия апаны иҗади шәхес булганын белә идек. Әңгәмә уңаеннан ул безгә сыйныфташлары белән мәктәпне тәмамлауларына 50 ел тулу хөрмәтенә язылган шигырен бүләк итте.

## САБАКТАШЛАР

Сабакташлар! Булдык тагын бергә
Олыгайганбыз тагын күп яшькә
Кайберебез теләп килмәгән
Кайсыларыбыз киткән кайтмаска.

Үскән чакта булды төрле хәлләр
Булгалады бәхәс, үпкәләш.
Ә шулай да матур хатирәләр белән
Күз алдыма киләсең, яшьтәш.

Уртак булды уен – шаярулар,
Уртак булды уй һәм хыяллар.
Маяк булды гомер юлларымда
Остазлардан алган идеаллар.

Язмышларны алдан белеп булмый
Кемдер үскән, кемдер ялгышкан.
Үпкәләмик Ходай язганына,
Гашыйк булып калыйк тормышка.

Әй, Сабакташ, уйнат гармуныңны
Җырлар белән үтсен гомерләр.
Безнең чәчкә бәсләр кунса кунсын,
Өшемәсен, ләкин күңелләр.

***Асия Исмәгыйлева,***
***ветеран педагог***



***/Истәлеккә – фотосурәт/***



Бу фотосурәттә Түбән Майна балалар бакчасында 2000 ел ахырында үткәрелгән Яңа ел бәйрәмендә катнашкан балалар һәм бакча хезмәткәрләре төшкән. Арткы рәттә уңнан сулга – бакча мөдире Асия Исмәгыйлева, кече тәрбияче Флера Гафиятуллина, пешекче Гөлсинә Гобәйдуллина, тәрбияче Фәридә Гафиятуллина. Тәрбияләнүчеләр төркемендә – 1994-1998 елда туган балалар.

**/ТАССР төзелүнең 100 еллыгына/**

## БАЛАЛАР БАКЧАСЫ ТАРИХЫННАН

Гәзитебезнең алдагы саннарында Түбән Майна авылында мәктәп тарихына багышланган мәкаләләр бастырылган иде. Бу санда балалар бакчасы, мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү тарихын яктыртырга булдык.

Кече яшьтәге балаларны тәрбияләү, әлбәттә, кешелек тарихы дәвамында барча халыкларда да тормышка ашырылган. Традицион җәмгыять шартларында әлеге мактаулы гамәл, беренче чиратта, әниләр, әбиләр, апа-абыйлар вазифасына кергән. Ул дәвердә мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен махсус тәрбия йортлары булмаган. Русиядә беренче балалар бакчалары XIX гасыр ахырында гына барлыкка килә. Ә безнең татар халкында ясле һәм бакчалар бары тик совет чорында гына ачыла башлый.

Архив документларында Түбән Майнада беренче балалар бакчасы 1921 елда телгә алына. Авылның беренче бакчасы, илдә ачлык башлану сәбәпле, балаларны туендыру максатыннан оештырылган булырга тиеш. Ул елны авылда тагын ятим балалар өчен приют та эшләгәнлеге билгеле. Картлар телендәге “балаларны җыеп, Америка боткасы ашаталар иде” дигән хәбәрләр шул дәвердәге хәлләргә кагыла.

Ул вакытта бакчада барлыгы 7 кеше эшләгән. Мөдир вазифасын Сәгъдиев Фәсхетдин дигән кеше башкарган (1931 елда кулак буларак сөрелә, 1937 “халык дошманы” дип атып үтерелә). Шәфигова, Сөнгатуллина, Низаметдинова дигән хатын-кызлар төркем тәрбиячеләре булырга тиеш (документта – “руководители”). Тагын Нигъмәтуллина, Хафизова, Мортазина дигән апалар пешекче, җыештыручы булып эшләгәннәрдер (документта – “прислуги”). Документта бакчадагы балалар саны китерелми. Ләкин хезмәткәрләр саныннан чыгып исәпләгәндә, балаларның да шактый күп булганлыгын фаразларга мөмкин. Чагыштыру өчен, 1921-1922 елда авыл мәктәбенең 4 бүлегендә (сыйныфында) 8-14 яшьләрдәге 148 бала укыгынлыгы билгеле.


Ачлыктан соңгы елларда балалар бакчасының ни рәвешле эшләгәнлеген ачыкларлык чыганаклар әлегә табылмады. Шулай да, ул заман шартларыннан чыгып караганда, бакча эшчәнлеге даими һәм тотрыклы булмаганлыгы аңлашыла. 1929 елның октябрь ахырында авылда беренче колхоз оештыру буенча узган җыелышта Әдәмсуыннан килеп эшләүче бер укытучы мәчетне балалар яслесе итеп файдаланырга тәкъдим итә. Әлеге хәбәрдән ул вакытта авылда балалар яслесе эшләгәнлеге һәм аның бинага мохтаҗлык кичерүе ачыклана.

Колхозлар оешкан 1930 елларда авылдагы балалар бакчасы “площадка” дигән исем белән билгеле. Мондый площадкалар, кагыйдә буларак, ел әйләнәсендә түгел, ә кызу эш вакытларында гына оештырылган. Ул елларда балаларны сәламәтлекләре буенча ике төркемгә бүлеп, аерым өйләрдә караганнар. Мондый чара исән балаларны авырулардан саклау өчен махсус эшләнелгән. Площадка һәм ясләдә эшләргә, гадәттә, яшь балалары булу сәбәпле колхоз эшенә чыга алмаган хатын-кызларны куйганнар. Аерым алганда, минем әбиләр – Фатихова Хөснеруй һәм Бикмөхәммәтова Галиянең сугышка кадәрге елларда тәрбияче булып эшләгәнлекләре билгеле.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны площадкаларга йөртеп карау тәртибе сугыштан соң да 1960 еллар ахырына чаклы дәвам итә.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

**/Котлыйбыз!/**




9 сентябрьдә 50 яшьлек юбилеен билгеләп үткән Насыйров Рафик Гомәр улын гомер бәйрәме белән котлыйбыз. Авылыбыз өчен дә, мәктәбебез өчен дә ихтирамга лаек булган җитәкчебезне котлап, озын гомер, сәламәтлек, гаилә иминлеге, иҗат уңышлары телибез.

Гафиятуллина Зөлфия апаның да 10 сентябрьдә гомер бәйрәме. Аңа да гаилә иминлеге, сәламәтлек телибез.

Сентябрь аенда VI сыйныф укучысы Минакова Әдиләне (10 сентябрь), IX сыйныфтан Мөхәммәтова Рузиләне (14 сентябрь) туган көннәре белән котлыйбыз. Укучыларыбызга укуларында уңышлар, сәламәтлек телибез.

**/Безнең уңышлар/**




28 сентябрьдә Чирмешән районында уздырылган Г.К.Гыйматдинов истәлегенә уздырылган Республикакүләм билбау көрәшендә егетләребез Нурматов Халид II урынны, Хәбибрахманов Ильяс III урыннарны алып кайттылар.

Шулай ук көнне Самара өлкәсе Чатырлы поселогында милли көрәш турнирында үз авырлыкларында Камалов Илдус I урынны, Хәйруллин Данил II урыннарны яуладылар. Егетләр арасында Камалов Илдус кубок һәм грамота, калган батырлар грамота белән бүләкләнде.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:**
**Әминә Туктамышева** **Алия Гыйззәтуллина**
**Виктория Нукина** **Нәзирә Әхмәтова**
**Зөлфирә Сафиуллина** **Рузилә Мөхәммәтова**
**Сара Насыйрова**